## *“Татар җыры фестивале”*

Бүген, 13нче октябрь көнне, “187нче номерлы күп профильле лицей”да укучылар тарафыннан оештырылган Татар җыры фестивале булып узды. Бу җыр фестивале Татарстан республикасында оештырылган “Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы”на багышланды. Әлеге чараны без укучыларның туган телгә карата булган мөнәсәбәтен уңай якка үзгәртү, туган теленә булган мәхәббәт тәрбияләү максаты белән, күренекле татар җыр авторалырының җырларына игътибар уяту нияте белән оештырдык. Төп шарт: сәхнәдә укучылар коллективы күмәкләшкән рәвештә татар авторының җырын башкарырга тиеш булдылар. Дөрестән дә, бу чара чын Татар җыры бәйрәменә әверелде. Сәхнәдә үзләренең осталыкларын 15 сыйныф төркеме күрсәтте. Аларны карап утырган тамашачы зур канәгатьлелек алып, төрле дулкынлану хисләренә төренеп, мөккибән карап алкышлап утырды. Ә җюри комиссиясе катнашучыларның осталыкларына, бердәмлегенә сокланып, үзләренең фикерләрен Диплом-номинацияләр билгеләде һәм истәлекле кечкенә бүләкләр белән шатландырдылар. Киләчәктә дә яшь башкаручыларга зур уңышлар теләп калабыз. Мондый чараларда тагы да актив катнашуларын көтеп калабыз.




Жыр фестивале


"Гүзәл туган
ягыбыз"
җыры


"Ай былбылым"
җыры
3 Г сыйныфы
2021


Җыр фестивале
2021


Жыр фестивале


Жыр фестивале

